ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 142 15.08.2019.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге
генераль планын раслау турында
үтенечнамә хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, «күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 24.07.2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, Монай авыл җирлеге Уставы нигезендә, генераль план проекты буенча гавами тыңлауларның беркетмәләрен һәм әлеге гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Монай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск муниципаль районы Советы алдында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлегенең генераль планын раслау турында үтенеч юлларга» (алга таба – генераль план).
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монай авыл җирлеге генераль планын раслау турында" 2019 елның 7 июлендәге 139 нчы карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм www.mendeleevsk.tatar.ru "Монай авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга
4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (басылып чыккан) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Монай авыл җирлеге
Советы рәисе Кириллов Р.М.